**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

2024 елның «19» ноябреннән — № 288

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2022 елның 03 августындагы 208 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2022 елның 03 августындагы 208 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә 1.3 бүлекчәсенең 1.3.2 пунктындагы 2 пунктчасында «интерактив формада» сүзләреннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

2 бүлекнең 2.3 бүлекчәсенең 2.3.2 пунктында «шәхси кабинет» сүзләреннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

2 бүлектә 2.5 бүлекчәсенең 2.5.1 пунктындагы 1 пунктчасында «мөрәҗәгать итү юлы белән» сүзләреннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

2 бүлектә 2.5 бүлекчәсенең 2.5.1 пунктынның 3 пунктчасындагы 3 абзацта «мөрәҗәгать итү юлы белән» сүзләреннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

2 бүлектә 2.5 бүлекчәсенең 2.5.2 пунктындагы 2 пунктчасында «итү юлы белән» сүзләреннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

2 бүлектә 2.5 бүлекчәсенең 2.5.3 пунктында «итү юлы белән» сүзеннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

2 бүлектә 2.7 бүлекчәсенең 2.7.1 пунктындагы 1 абзацында «документлар кабул итүдә» сүзләреннән соң «(әлеге административ регламентка 5 нче кушымта),» сүзен өстәргә;

2 бүлектә 2.7 бүлекчәсенең 2.7.1 пунктындагы 5 пунктчада «гариза» сүзеннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

2 бүлектә 2.7 бүлекчәсенең 2.7.2 пунктында «итү юлы белән» сүзеннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

2 бүлекнең 2.14 бүлекчәсендәге 2.14.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә аларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керүен тәэмин итү максатыннан түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

1) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына (торак, иҗтимагый һәм җитештерү биналарына, төзелешләренә һәм корылмаларына, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка оешмалар урнашкан урыннарга), ял итү урыннарына һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз кереп йөрү өчен шартлар;

2) шәһәр, шәһәр яны, шәһәрара элемтәдә тимер юл, һава, су транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында, элемтә һәм мәгълүмат чаралары (светофорларның һәм транспорт коммуникацияләре аша җәяүлеләр хәрәкәтен җайга сала торган җайланмаларның тавыш сигналлары белән кабатлауны тәэмин итә торган чараларны да кертеп) тоткарлыксыз файдалану шартлары;

3) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм чыгу, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге;

4) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләренең өзлексез бозылуы булган инвалидларны озата бару һәм аларга социаль, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектларында ярдәм күрсәтү;

5) чикләнгән тормыш эшчәнлеген исәпкә алып, инвалидларның бинага, бүлмәләргә тоткарлыксыз үтеп керүен һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алуын тәэмин итү өчен җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидларга кирәкле авазлы һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифты белән башкарылган билгеләр ярдәмендә кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәче кертү;

7) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм халыкны социаль яклау өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән махсус укытуны раслый торган һәм формасы һәм тәртибе буенча бирелә торган документ булганда, озатучы этне кертү;

8) хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга күрсәтелә торган хезмәтләрне башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә алырга комачаулый торган каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.»;

2 бүлектә 2.14 бүлекчәсенең 2.14.3 пунктында «1-4» саннарын «1-8» саннарына алмаштырырга;

2 бүлекнең 2.15 бүлекчәсенең 2.15.2 пунктында 4 пунктчасындагы 5 абзацта «кулланып» сүзеннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

2 бүлектә 2.16 бүлекчәсенең 2.16.1 пунктындагы 2 пунктчасында «кулланып» сүзләреннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

2 бүлектә 2.16 бүлекчәсенең 2.16.1 пунктындагы 6 пунктчасында «итү юлы белән» сүзләреннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

2 бүлектә 2.16 бүлекчәсенең 2.16.2 пунктында «гариза» сүзләреннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

2 бүлектә 2.16 бүлекчәсенең 2.16.4 пунктындагы 1 абзацында «ысулы белән гамәлгә ашырыла» сүзләреннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

2 бүлектә 2.16 бүлекчәсенең 2.16.4 пунктындагы 4 абзацта «итү юлы белән» сүзләреннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

3 бүлектә 3.2 бүлекчәсенең 3.2.3 пунктындагы 1 абзацында «консультация» сүзләреннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

3 бүлектә 3.2 бүлекчәсенең 3.3.3 пунктындагы 1 абзацында «аркылы» сүзләреннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

3 бүлектә 3.5 бүлекчәсенең 3.5.3 пунктындагы 3.5.3.2 пунктчасының 1 абзацында «муниципаль хезмәт аркылы» сүзләреннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

3 бүлектә 3.5 бүлекчәсенең 3.5.3 пунктында 3.5.3.2 пунктчасындагы 3 абзацында «кулланып» сүзеннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә;

3 бүлектә 3.6 бүлекчәсенең 3.6.1 пунктындагы 5 абзацта «яки аркылы» сүзләреннән соң «Бердәм,» сүзен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов